Рузил Фазлыев

# Шигъри көндәлек

Шигырь. Том 9. Стихи

Рузил Фазлыев

# Шигъри көндәлек. Шигырь. Том 9. Стихи

«Издательские решения»

**Фазлыев Р.**

Шигъри көндәлек. Шигырь. Том 9. Стихи / Р. Фазлыев — «Издательские решения»,

ISBN 978-5-00-591876-5

Шигырь телендә язылган истәлекләр, фикерләр, кичерешләр… Бүгенге көнгә кадәр язылганнарны булдыра алганча электрон вариантка күчерелеп бетерелде иншааллаһ… Укучылар өчендә уңайлы булыр дип уйлыйм. Тормыш туктаусыз үзгәрә, яңара, без уйламаган, хыялланада алмаган мөмкинлекләр ачыла… Шигырь белән бергә бер калып, уйланырга таныш фикерләрне танырга була. Үзең өчен еракта калган хәтирәләр кабатланып алган кебек.

ISBN 978-5-00-591876-5

© Фазлыев Р.

© Издательские решения

# Содержание


Сагынулар 6
Җаның бар 7
Еллар буе 8
Кәфирун 9
Үткәннәр, көткәннәр 10
Елларның Сабантуе 11
Гади җан иясе 12
Чәчәк атканда 13
Язам әле 14
Артык белән… 15
Намазлык 16
Җыр кебектә 17
Кое казу, суын табу 18
Җәйге төннәр 19
Актаныш 20
Күңел көче 21
Хисләр диңгезе 22
Юл 23
Сөяркә кебек (нәсер) 24
Тәрҗемә… 25
Шәхси юл 26
Озын да, кыска да 27
Кыек юл 28
Тәүбәсез дога 29
Ямьсезме дөнья 30
Син кайгырма 31
Тау аслары 32
Пешкән җиләк 33
Онытылганнар 34
Йорт хайваны 35
Шундый юллар 36
Кичке вакыт 37
Их, Сөн буе 38
Дөнья кая бара? 39
Укы дигән 40
Печән чоры 41
Эчке хисләр 42
Юлың – биеклегең 43
Конец ознакомительного фрагмента. 44

# Шигъри көндәлек
# Шигырь. Том 9. Стихи

# Рузил Фазлыев

© Рузил Фазлыев, 2023

ISBN 978-5-0059-1876-5 (т. 9)
ISBN 978-5-0056-9347-1
Создано в интеллектуальной издательской системе Ridero

# Сагынулар

Сагынулар авыр була икән,
Онытулар мөмкин булмаса.
Күңелләрдә калып бер моң булып,
Кабатланып, һаман җырласа.

Еракларда, ләкин якын кебек,
Үтә алмаслык кына аралар.
Калмагандыр артык тирән булып,
Күптән төзәлгәндер яралар.

Язмышларның бизәкләре булып,
Шуңа кабат, тели күңелләр.
Шатланулы офтанулар алар,
Сагынулар кайгы түгелләр.

Сагынулар килә җитәкләшеп,
Моңнар белән күңел тулганда.
Гомернең ул, бәхет урыннары,
Сагынырлыклары булганда.

Сагынма дим, үзем сагынсамда,
Кай якларга күңел тартсада.
Күңел, үтеп адашулар аша,
Узар юлын күптән тапсада.

# Җаның бар

Җан азыгы, җанлы җансыз,
Гади ул, бер уйласаң.
Бу җирдәге урыныңны,
Артык биек куймасаң.

Барлыгыңны, юклыгыңны,
Җаның булу күрсәтә…
Җанга нидер җитми кала,
Ниләр генә күрсәк тә.

Җан белән тән бер бөтендәй,
Тәндә җанның «оясы».
Тәнне саклый белгән кебек,
Җанныда, бар тоясы…

Җылы сүзләр, җылы караш,
Ризык табу җаныңа.
Онытмаска юл табарга,
Үз җаныңның «янына».

Рухи байлык – җан азыгы,
Табыйк, таба алганын.
Сине кеше итеп тота,
Тәннәреңдә җан барың.

Тәннәр өчен җаннар кирәк,
Җансыз тәннәр – мәетләр.
Яшәсәк мәетләр кебек,
Ходай безне гаепләр…

# Еллар буе

Үзеңә сорау бирә алып,
Булдымы сораганың.
Туган җиргә кайта алып,
Урамнар ураганың…

Ашыкмыйча салмак кына,
Урамнан атлаганың…
Очрагандай шул вакытта,
Күпме эзләп, тапмаганың.

Тау башында басып торып,
Офыкларны «гизгәнең».
Үткәннәрне күңел белән,
Тойганың һәм сизгәнең.

Су буенда, ярга басып,
Булдымы уйланганың
Сакланылган әле һаман,
Ни чаклы уйлар барын.

Кабат урап калыр өчен,
Күпме таныш юллар бар.
Урам әйләнүләр өчен,
Язмыш биргән еллар бар.

# Кәфирун

Кәферлек ул начар гадәт түгел,
Бик тиз генә булмый төзәтеп.
Ансат кына олы ялгышларын,
Язмышларның булмый үзгәртеп.

Тәүбә аркылы бары юллары бар,
Кәферлектән була качарга.
Шайтан кочагыннан ычкынырга,
Иман дигән юлны ачарга.

Юлның бары берсен сайлап була,
Ике юлдан кемдә баралмый.
Юлын бик еш алыштыручы да,
Аңлый алмый, барыбер табалмый.

Кеферлек ул җилгә каршы. ию,
Андыйларның акыл томанлы.
Аңлатуның хикмәтлесе кирәк,
Кеше күзен ача торганы.

Кәферлек ул кеше гомерендә,
Сыналырлык, ачы язмышы…
Бергә үрелсәдә язмыш белән,
Үзе кылган гамәл – ялгышы.

# Үткәннәр, көткәннәр

Алда юллар ачылалар,
Үткәннәре ябыла.
Хыяллар сүнгән булмаса,
Барыр юллар табыла.

Алдагылар якты кебек,
Караңгымы үткәннәр.
Онытып торып бер азга,
Язмышыңны сүккәннәр.

Кемгә сораулар бирергә,
Борылып карап артыңа.
Әллә кайбер мизгеленә,
Күңел һаман. талпына.

Үткәннәре, сынау булды,
Алда көтә, сынаулар…
Бөтен юллары гомернең,
Имтиханнар, сынаулар.

Хәрәккәттә үзгәрешләр,
Йөрмәсәң күрмисең шул.
Бер мизгелен, алдагысын,
Язмышның белмисең шул.

# Елларның Сабантуе

Сабантуйлар кабатлана,
Елларны санагандай.
Майданнарга бергә җыеп,
Бер сынап карагандай.

Елның, җәйнең уртасында,
Үза Сабантуйлары.
Кемнәр өчен быел әле,
Үзләренең туйлары…

Исәннәр барсы килгәндәй,
Бу олы җыеннарга.
Бәйрәмедә хайран була,
Майданга җыелганда.

Бәйрәм төсен тою өчен,
Анда булулар кирәк.
Күрешүәр, очрашулар,
Кабатланулар, сирәк.

Шаулап үтсен Сабантуйлар,
Татар Иле бәйрәме.
Кабатланып торып җирдә,
Халыкның һәм – җәй яме.

# Гади җан иясе

Яхшы белән начар арасы,
Шул кадәрле ара еракмы.
Кайвакытта аеруы кыен,
Шатланучы белән елакны.

Җылы хисләр кинәт кабынганда,
Кем кайдагы җиргә үрелә…
Селәгәйнең тәмен татый татый,
Нидер җыя күңел түренә.

Кеше өчен бәхет тавы кебек,
Сөя алу белән, сөелү…
Иң тәбигый, кеше омтылышы,
Сөю күлмәгенә төренү.

Озакламый барсы югаласы,
Ихлас булып туган хисләрең.
Төшләр кебек җуелада бетә,
Йокыларсыз үткән кичләрең.

Җүләрлеге булып язларыңның,
Ул вакытны йоклап калмаска.
Яшәешне дәвам итү өчен.
Язган юлны ялгыз бармаска.

Барысыда алдан куелганга,
Кеше өчен кызыл флаглар.
Ризыгың аяк асларында.
Эзлисе юк аны ерактан.

# Чәчәк атканда

Иртәләрен карыйм урамнарга,
Тәрәз карышында, юкәләр.
Еллар саен биегерәк булып,
Үсәләрдә алар, үсәләр.

Бөреләнеп юкә чәчәкләре,
Җәйләр уртасында ачыла.
Юкә чәчәкләре шифа бирә,
Җыяр өчен күпләр, ашыга.

Өзмәдем мин юкә чәчәкләрен,
Хозурланып, бары карадым.
Юкәләрне көндә күрә алу,
Шифалырак диеп санадым.

Юкә агачы, чәчәк ата быел,
Биегерәк булып йортлардан.
Күңеленә шифа гына җыя,
Юкә агачын күреп сокланган.

# Язам әле

Язам әле, язылганда,
Егылмыйча, абынганда.
Нидер әзли әле күңел,
Шатлана, табылганда.

Дөнья, ерагая кебек,
Мәшәкатләре белән.
Җиһанның киңлекләрен,
Бераз башкача күрәм.

Башкачарак уйлар килә,
Гадиерәк хыяллар.
Кайберләре йокылардан,
Яңа гына уянган.

Иртәләр, кичләрдәй тыныч,
Җәйләр үтмәсләр кебек.
Шатлыкка сәбәп эзлисең,
Җирдә бер үзең кебек.

Вакыт шулай үзгәртәме,
Әллә, тормыш агышы…
Бетмәс кебек, беркайчанда,
Җирдә гомер сагышы.

# Артык белән…

Тамашаны бәйрәм белән бутап,
Барып життек әллә кайларга.
Арты белән халык концерт карый,
Сабантуйлар барган майданга.

Сабантуйлар олы базар кебек,
Кайвакытта йөзләр кызара.
Кайберәүләр анекдотта язган,
Әрмән кебек булып кылына.

Клоуннар, тозсыз булган мәзәк,
Матурлыймы Сабантуйларны…
Әллә алар безне ялгыштыра,
Оныттырып «туйда» булганны.

Милли бәйрәм, милли уеннары,
Саклап килә алган бай мирас…
Онытылып, әллә белмәгәннән,
Калып бара ахыры бик тә аз.

Шаблон белән, венегерет ясап,
Бәйрәм диеп, үтәп чаралар.
Таяк тыгып, аяк арасына,
Атлар булып кемнәр чабалар.

Сабантуйлар шулай картаямы,
«Яңартулар» белән бозылып.
Үтеп бара әллә күз алдында,
Сабантуйлар чоры, узылып…

# Намазлык

Бусагасы иман ишегенең…
Уку урыннары намазның.
Ишетүгә, чакыруы булган,
Моңлы авазларын азанның.

Утырауы кебек зур җиһанның,
Ышанычлы булган юлыдыр.
Якын булсын, кул астында гына,
Намазлыгың – намаз урының.

Мәчетләре Аллаһ йорты булса,
Йортта, намазлыкта гыйбәдәт.
Иман капкаларын ача алу,
Иң саваблы булган бу гадәт.

Намазлык ул тәһәрәтле урын,
Ихлас булган уйлар өченгә.
Гыйбәдәт һәм догаларың белән,
Барлык булганнары эчендә.

# Җыр кебектә

Гомерләрне тоеп була икән,
Чагыштырыр әйбер эзләсәң.
Үз язмышың сине борчымый…
Уйланмыйча гына йөрмәсәң.

Җыр кебектә, кеше язмышлары,
Үз җырыңны таба алганда.
Эзе булып җирдә яшәүләрнең,
Җыры бетеп, моңы калганда.

Җырнында шундыйлары була,
Кабатлана алмый торганы.
Дәртле булган җырлар урынына,
Истә калып тирән моңнары.

Язмыш алда, гомер үтә бара,
Җырның да бит була азагы.
Төренсәдә алар тирән моңга,
Җырлар булмый, язмыш газабы.

Үз вакыты, үзе урыннары,
Тота белә алу ул «кошны».
Белү кыен алдан, язмышыңны,
Оттырумы, әллә отышмы.

# Кое казу, суын табу

«Энә белән кое казу» дигән,
Татарның бер тирән мәкале.
Эчтәлеге аша ишетелә,
Асылы һәм аның мәкаме.

Китап үзе, гыйлем капчыгы ул,
Язмышларда… анда язылган.
Укый алып, аны укыганда,
Бар гомерең анда, ябылган.

Киләчәгең анда билгеледәй,
Күпме үтелгән анда юллар бар.
Үзеннекең танып алып була,
Бихисап күп булган юллардан.

Тирәнлеге, кое гына түгел,
Уйларыңны әгәр җигә алсан.
Байлыгында арта гына бара,
Нәфесеңне генә җинә алсаң.

Ишетмәсәң китап «сөйләгәнне»,
Ялгышларга юллар ачылган.
Ничә буын аша, сабак булып,
Үтә, үтә кеше башыннан.

# Җәйге төннәр

Җәйге төннәр тыныч вакыт,
Йолдызлы да, җылы да.
Туктап торып яллар итә,
Җәйнең дәртле җырыда.

Тынып кала кошларыда,
Көннәр буе сайраган.
Әйтерсеңлә бөтен җиһан,
Тынычлыкны сайлаган.

Бардыр инде сирәк мирәк,
Йокысызлар, парлылар.
Кемнәр төндә бар хисләрен,
Үлчәүләргә салдылар…

Тыныч төннәр, таңга кадәр,
Эндәшмичә түзә алыр.
Яралары була калса
Таңнар җитеп, төзәлер…

# Актаныш

Агыйдельнең биек ярларында,
Тау башында тора Актаныш.
Ядкәредәй булып милләтенең,
Татарларга хәзер бик таныш.

Яшә шулай, якты маяк булып,
Тарихларда калып, макталып.
Агыйдельнең агымнары кебек,
Озак гасырларга сакланып.

Ак исемнән, ак хыяллар туып,
Ак юллары әле салыныр…
Актанышым диеп җыр сузучы,
Киләчәгендә дә табылыр.

Көнчыгышы булып милләтенең,
Син калырсың һаман ак булып.
Сәхнәдәге Агыйдельдәй булып,
Макталырлык матур як булып.

Тау башында үсә Актаныш,
Ак булуы калыр сакланып.
Бед (з) некеләр диеп горурланып,
Сокланырлык булып – таң калып.

# Күңел көче

Күңел тарту, күңел тартылуы,
Еракларга таба күчәме…
Тоймаганга, әллә онытканга,
Якын гына булган кичәне.

Күңел тарта, әйтми сәбәбен,
Әйтәләр бит,«тартса күңелең».
Кыен була кабул итүләре,
Күңелеңә якын түгелен.

Күңел «сүзе», юллар табу кебек,
Кайсы якка, кайчан баруның.
Бик кирәк диеп уйланылган,
Урыннарга бармый калуның.

Сиңа сайлый мөһим булганнарын,
Кәлебеңә ярый торганын.
Гамәлләр бит шуңа әйтеп бирә,
Күңелеңнең нинди булганын

Кәлебләрдә кебек хисләр башы,
Күңел безне, сүзсез кисәтә.
Шуңа күрә, ялгыш эшләр туа,
Күңел тартмаганын сизсәктә.

# Хисләр диңгезе

Язам әле шигырь кебек итеп,
Куплетларга салып сүзләрне.
Хисләр өстәп, шигырь арасында,
Хыял диңгезендә йөзгәнне.

Кем булмаган андый диңгезләрдә,
Йөзмәсәдә, кереп караган.
Кемгә аңларга аның тирәнлеген,
Ярда басып тору, яраган.

Диңгез кебек хисләр җыелганда,
Күбекләнсә биек дулкыннар.
Чын шигырьләр диңгез суыдай,
Бераз гына тозлы торсыннар.

Шигырләр ул, хисләр диңгезедәй,
Ә юллары, дулкын тезмәсе.
Бар хисләрең дулкын арасында,
Әллә каян түгел эзләсе.

Күтәрелә, аннан түбән төшә,
Шигырьдә дә дулкын телләре.
Кемнәр аны ачык ишетә ала,
Бик күпләрнең, бардыр күргәне.

Диңгез өчен киңлекләре кирәк,
Сыя алырлык, булган сулары.
Хис диңгезе кебек шигырләрнең,
Мөлдерәмә булып тулганы.

# Юл

Ялыкмыйча тормыш юлларында,
Ниләрдән соң һаман туймадым.
Күп яшәдем диеп, әйтер идем,
Акылымны әле җуймадым.

Җиһан киңлекләрен аңласамда,
Биекләргә хисләр сикерми…
Хыял артларыннан иярәсең,
Барасыңда, барып җителми.

Юллар бетеп туктый ала микән,
Кеше аны үзе күрерлек.
Вакыт кына хәбәр бирә кебек,
Кыскарыуын аның белерлек.

Дәрес барсә тәнәфесен көтеп,
Озак кебек вакыт үтелә.
Өй эшләре әзер булмаганда,
Шундый курыку хисе көтелә.

Сәер уйлар башта кунак була,
Уйландырып әллә куркытып.
Атлаганда ашыкмыйча гына,
Язмыш юлларына юл тотып.

# Сөяркә кебек (нәсер)

Акча шундый әйбер инде ул,
Бер керә дә, бер чыга.
Аның кереп чыгуына,
Башыңа төшкәч, чыда.

Колы гына булу түгел,
Акча сине басканда.
Рубльнең син кәләше,
Кая гына качсаңда.

Сине эзләп йөрмидә ул,
Ә син, «өмет итәсең…»
Уйларгада мөмкин түгел,
Ничә тапкыр «китәсен».

Керә чыга, иртә кичен,
Шомара кесәләрең.
Күпме җыелырлар иде,
Бушаган шешәләрең.

Киендерә, чишендерә,
Шәп шәрәдә калдыра.
Кесәңдәге «үз байлыгың»,
Тезләндерә алдына.

Ике кулга, өч бияләй,
Кирәге чыгар, диеп.
Бәлки башта караргадыр
Өчесен бергә киеп…

# Тәрҗемә…

Борынгы һинд дәүләтендә,
Язылган олы китап.
Барысында бу дөньяда,
Бетермәс өчен бутап.

Белгәннәр бар, белмәгәннәр,
Ишеткәннәр күргәннәр.
Кызганычы, күпме халык,
Белә алмыйча үлгәннәр.

Шахмат кебек 64 тән,
Китапның эчтәлеге.
Язылуы бик тәфсилле,
Мәхәббәт нечкәлеге.

Татарчага тәрҗемәсе,
Бердә булмады микән.
Татарыма бүләк булсын
Татарча- «Чулман иртән».

Ятсада, торганда да,
«Китап укып утыра».
Ничек булган китап исеме?
Була. а.а.у.р.!
(«Чулман иртән» – русча).

# Шәхси юл

Шәхси, ягъни үзенеке генә,
Була урыннары кешенең.
Төзәтергә кирәк түгелләре,
Үзе сайлап кылган эшенең.

Ялгышлары бары үзенеке,
Саваплары бары үзенә.
Үзгәрәме кеше язмышлары,
Колак салып кеше сүзенә.

Кеше сайлый үзе тормыш юлын,
Озак эзләп кайчак, табыла.
Кайчагында юллар ачылалар,
Көтмәгәндә, кайчак ябыла.

Олы бәхет, бергә була алу,
Тою барын, туган, дусларны.
Тиеш сүзен читкә куеп торып,
Эшли алу күңел кушканны.

Ният булып, уйлар үсә алса,
Гамәлләргә алар әйләнеп.
Гомер озынлыгы сузылмый ул,
Беркемгә дә булмый «бәйләнеп».

# Озын да, кыска да

Армиядә булып кайта егет,
Бик күпләрне күреп өйрәнеп.
Артык тырышудан микән инде.
Кайберәүләр кайта өйләнеп.

Бер мисалы булып бу тормышның
Кыска гына, булган арасы.
Якты дөнья, ул армиядә кебек,
Ә аннаң соң, күпме барасы.

Кыска гына тоелсада гомер,
Мәңгелеккә дәрес аласың.
Өлгерсәңдә күпне аңларга,
Җитешмичә, күпме каласың.

Белгәннәрең олы юлдаш кебек,
Белмәгәне, димәк язамаста.
Мәңгелеккә әзер булмаганга,
Юлдаш итеп беркем алмаста.

Ышанмасаң кичләр буласына,
Синең уен, синең эшләрең.
Кояш баеп, йокы кермәгәндә,
Ничек үтәр микән кичләрең…

# Кыек юл

Турылары, бормалысы була,
Була юлларның бит, кыегы.
Адашсаңда, адашмаган кебек,
Аңлар өчен авыр, кыены.

Такыр кебек юллар бүген өчен,
Еракларга уйлар салмасаң.
Барам әле, диеп уйлап кына,
Кая икәнен аңлый алмасаң.

Кыек юллар алар шуңа күрә,
Ялгыш уйлар, кыек гамәлләр.
Аерылу үзе өммәтеңнән,
Ишетелмәс булган сәләмнәр.

Ялгызлыка дучар итә алыр,
Андый юлда озак булганда.
Кисәтүче юлдашыңда булмас,
Үз үзеңә тозак корганда.

Кыек юллар адаштыралар да,
Корыр чишмә булып, акмаслык.
Үкенече булып язмышыңның,
Кыйблаңны җирдә тапмаслык.

# Тәүбәсез дога

Дога кылу, сорау ялварудыр,
Бер Аллаһтан мөмкин булганын.
Ничек итеп сорап була алыр,
Булмаганда тәүбә кылганың.

Намаз алды тәһәрәтең кебек,
Тәүбәләр ул, шулай пакълану.
Бу тормышта белеп яки белми,
Кылган гөнахлардан аклану.

Башны иеп, түбәнчелек белән,
«Ярлыка», дип әйтә алырга.
Дога өчен, юлын ачар өчен,
Хаталарның барсын танырга.

Ул бурычлар гомер җыелганда,
Буламы соң, нидер сорарга.
Язмышыңа бәйле халәтеңне,
Башкача бит булмый юрарга.

Гөнахларың, олы бурычларың,
Тәүбә бары, чыгу юллары.
Алар аша гына уза ала,
Догаларның кабул булганы.

# Ямьсезме дөнья

Күрер өчен дөнья матурлыгын,
Карый белү кирәк, аңларга.
Кояш калыкканда офыкларда,
Иң беренче, карап таңнарга.

Башлануын сизеп көннең, елның,
Кадерләрен белеп гомернең.
Тояр өчен күңел күзе белән,
Дөнья һичтә ямьсез түгелнең.

Күңел, эзли, күрә теләгәнне,
Матурлыкны яки ямьсезне.
Карау җитә өскә, һаваларга,
Аяз күкләр әллә ямьсезме…

Дөнья ямьсез кебек була икән,
Алар бары ямьсез күңелгә.
Калебеңә карап алу кирәк,
Ямьсез булып дөнья күренсә.

Дөнья ямьсез, уйлар чолгаганда,
Шикле булып туса фикерләр.
Бер үк җиһан, төрле кеше өчен,
Ямьле яки ямьсез ителгән.

# Син кайгырма

Син кайгырма авыр вакытларда,
Бирә алмый кайгы, җиңеллек.
Кайгырулар түгел, юанычың,
Сабырлык ул, аны җиңерлек.

Үзгәртәлми кайгы язмышыңны,
Юлдаш булмый сиңа юлыңда.
Сабыр гына узып китә ал син,
Кайгы калсын, булган урында.

Син кайгырма гади сынауарга,
Дөньялыкта килсә, көнеңдә.
Аллаһының ихтибары кебек,
Язылганы сиңа бүгенгә.

Синең кайгың бәлки уйландырыр,
Тәүбәләргә ачып юлларын.
Барәкәте, әйткән шөкерләргә,
Оныттырыр кайгы булганын.

Иманлыны кайгы җиңә алмый,
Сыенырга, чөнки Аллаһ бар.
Сыналулар ул, җирдә яшәгәндә,
Барысыда, безгә Аллаһтан…

# Тау аслары

Тау астында дисәң, аңлашыла,
Олы болын, Кылыч башлары.
Тау башыннан, уч төбендә кебек,
Матурлыгы, чиктән ашканы.

Кочак җитә алмас, бу җиһанның,
Матурлардан, матур кисәге.
Саклаunion бердә үзгәрмичә,
Балачаклар «эзе», кичәге.

Үзе матурлыгы һәр урынның,
«Тау аслары», тагын бар әле…
Вакыт табып җәйге мизгельдә,
Берәр тапкыр күзләр сал әле.

Һич булмаса, фоталарга кара,
Хәтереңне «чайкап» алсыннар
Язмышыңның бер кисәге булып,
Күңел түрләреңдә калсыннар.

# Пешкән җиләк

Җәйләр җитеп җиләк пешә,
Кызарып, алсуланып.
Китә кебек ул җиләктән,
Күңелләр ярсуланып.

Җиләкләр пешкән вакытлар,
Кабатлана ала микән.
Пешеп өзелгән җиләкне,
Кемнәр искә ала микән.

Пешкән җиләк өзеләсе,
Күрүчеләр булганда…
Өлгерүдән, бик кызарып,
«Өзегез» дип торганда.

Җәйләр саен пешә җиләк,
Коела йә, өзелә…
Пешкән җиләк җәен генә,
Кала алмый, көзенә.

Җиләк пешә, өлгерә дә,
Җәйләр өчен тәм кебек.
Пешкән җиләк татый алу,
Күңелләргә ямь кебек.

# Онытылганнар

Вакыт шулай хәл иткәндәй,
Онытылганнар, югалганнар,
Сызылгандай хәтерләрдән,
Кайчан якын була алганнар.

Кемнәр кайда, кемнәр булып,
Ни хәрәкәтләрдә микән…
Бакыйлыкка күчкәннәре…
Кемнәр икән, әле исән…

Билгесезлек хәбәр юктан,
Шактый инде вакыт узган.
Тоташтыра торган күпер,
Төзәтмәслек булып тузган.

Кыска булып уртак язмыш,
Өзекләнгән тоташ юллар…
Аерылышулар, уйда булмый,
Күпме вакыт шундый булган.

Вакытлыча кебек хәзер,
Язмышларның кисәгедәй.
Узылганда, онытылган,
Тормыш юлы исәбедәй…

# Йорт хайваны

Кеше яши файда өчен,
Янәшәдә, хайван белән.
Үлчәнәдер ул вакытлар,
Еллар белән, айлар белән.

Эт, мәчеләр, өйдә бергә,
Сыерлары савар өчен.
Кош кортлары асыравы,
Ит, йомырка табар өчен.

Бергә яшәү хайван белән,
Үзгәртмиме кеше аңын…
Онытмыймы вакыт, вакыт,
Тирә якта кеше барын.

Гел булышып хайван белән,
Китермиме хайванлыкка.
Кеше яши алыр микән,
Яннарында хайван юкта.

Хайван кебек кенә караш,
Хисләренә калмый урын.
Файда көтеп бер береңнән.
Бөтен тормыш шулай узыр…

# Шундый юллар

Таныш түгел юллар буйлап,
Гомер юлларында барабыз.
Тәүге тапкыр; инде булганыннан,
Үз юлларыбызны табабыз.

Яңа безгә, тормыш тану юлы,
Ничә буын аны үтсәдә.
Әзер калсын диеп, төзеп безгә,
Маңгай тирен күпме түксәдә.

Юл хисабы, гомер озынлыгы,
Һәр кешенең үэе сукмагы.
Юллар белән бергә аралашып,
Тәкъдир булып безгә кушканы.

Ашыкмыйча, алдашмыйча гына,
Иң кыены… аны үтүе.
Үкенече: Кыйбласыз килеш,
Вакытларның үтеп китүе.

Әзер юллар, без төзисе түгел,
Ул юллардан бары, узасы.
Саклый юлда әдәм балаларын,
Ихлас итеп кылган догасы.
…Яшәешнең шундый йоласы.

# Кичке вакыт

Кояш баеый ерак көнбатышта,
«Агыйдельнең аргы ягында».
Офыкларга кереп югала ул,
Күкләр алсуланган чагында.

Кояш сүнә кебек, баеганда,
Якты нурларын ул, яшерә.
Нурлар саны тиңләшә дә кебек,
Кояш гомеренең яшенә.

Караңгылык килә аңа алмашка,
Туктап тора күпме хәрәкәт.
Көн яктысы гына бирә кебек,
Яшәү өчен безгә бәрәкәт.

Төннәр үтә кайчак таңны көтеп,
Аерыла алмый яктыдан.
Шунан яшәп килә чагыштыру,
Төннәр шикле, көннәр яхшыдан.

# Их, Сөн буе

Сөн сулары, чишмә башы,
Анда туып үскәнгә.
Сөн агымнарына карап,
Балачаклар үткәнгә

Җыелырга иде бергә,
Сөн буе малайлары.
Чәчләренә корау төшкән,
Замана агайлары.

Ярларында басып торып,
Күзәтеп агымнарын.
Сөн суыдай, гомерләрнең,
Агымда баруларын.

Сөн буеннан күпме язмыш,
Агымнарын башлаган.
Күпмеләре, таба алып,
Бәхет юлын ачмаган…

Сөн буйлары уйландыра,
Искә килеп төшкәндә.
Таллар белән, ярындагы…
Бергәләшеп үскәнгә.

Их, шул Сөн буйлары нигә,
Күңелдә калган микән.
Язмыш буе безне онытмый,
Озатып барган микән…

# Дөнья кая бара?

Кая бара дөнья, кая бара,
Аптыраштa кайчак калабыз.
Дөнья түгел без үзебез ахыры,
«Икенчерәк» юллар табабыз.

Кая барсын… шөкер итми генә,
Биргәннәрнең барсын алабыз.
Югалына тормыш бәрәкәте,
Ерагая бара арабыз…

Бу дөньяның без тузаны гына,
Язмышларның ямен тапмасак.
Барыр юлның, ачык ишекләрен,
Үз кулыбыз белән япмасак.

Кая бара …җитә алырлыкмы,
Безнең акыл, аны аңларга.
Яшәргәме әллә, шөкер итеп,
Тезелешеп аткан таннарга.

Өмет булып, иртәләрең килеп,
Кояшлы көн булса бүгенең.
Язмышларың якты дөнья белән,
Икесе бер булып «үрелер…»
…Кая барылганы күренер.

# Укы дигән

Караңгылык, олы кара пәрдә,
Рухи яктан, була сукырлык.
Китап сүзен кабул итә алмый,
Вакыт булмый, аны укырлык.

Гыйлем сүзе, белү хикмәтедер,
Таныш булмаганны, яңаны.
Таба алу, җиңел үтә алу,
Бик ерактай булган араны.

Соң булалмый, белем чишмә суын
Кайчан гына татый алсаңда.
Үз халәте, кеше күңеленең,
Гомер, татый алмый калсада.

Уң булсын бит диләр, соң булсада,
Кешенең бит узса гомере.
Аллаһ кушкан, шуңа билгеле дә,
Гыйлем юлы авыр түгеле…

# Печән чоры

Өмәләре булып җәйнең,
Килә «печән өсләре».
Күмәкләшеп эшләгәндә,
Бик тиз җиткән кичләре

Печәнгә дип, иртәләрен.
Атларның җигелгәне.
Яңгырлар яуганчы диеп,
Чабылып, өелгәне.

Урак өсте алларыннан,
Эшләнә торганнары.
Ашлык сугуга ошаган,
Җыйганы, урганнары.

Кышка җитәрлек ризык,
Хәстәрләү вакытлары.
Ашыгулар, өметләрдә,
Сизелеп вакыт тары.

Кыска вакыт печән өсте,
Җәедә… үтеп китә.
«Җәйнең бер көне», диләр бит,
«Кышын туярга җитә:.

# Эчке хисләр

Кыен була, ялгыз калулары,
Күңелеңә иптәш тапмасаң.
Шәйләмичә, тапмый таяныч,
Тормыш юлларыңнан атласаң.

Боз шикелле күңел суынганда,
Эсселектән кайчак көйгәндә.
Хисләреңә җавап өчен генә,
Аңламыйча гына сөйгәндә.

Үкенечле булып, югалганнар,
Киткәннәре синең тарафтан.
Бишектәге яшь баладай булып,
Мәхрүм булу җылы караштан.

Хыялларың һаман бар шикелле,
Чакыралар алар, кай якка.
Кичүләре үтелмәгәнгәме,
Елгалары әле сай чакта.

Эчке хисләр тышка чыгар кебек,
Югалырлар кебек, түгелеп.
Ерактагы, офык артларыннан,
Ялгызлыкмы, ала күренеп…

# Юлың – биеклегең

Сиэелмидә үтеп бара инде,
Быелның да матур җәйләре.
Гомер юлын тагын бизи алып,
Хәтфә яшел келәм җәйгәне.

Ә көзләре, бәхет булып килә,
Унышлары булып гомернең.
Үткән юллар озын булсаларда,

# Конец ознакомительного фрагмента.

Текст предоставлен ООО «ЛитРес».

Прочитайте эту книгу целиком, купив полную легальную версию на ЛитРес.

Безопасно оплатить книгу можно банковской картой Visa, MasterCard, Maestro, со счета мобильного телефона, с платежного терминала, в салоне МТС или Связной, через PayPal, WebMoney, Яндекс.Деньги, QIWI Кошелек, бонусными картами или другим удобным Вам способом.